**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2016 елның 3 октябре № 56

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «җирле референдум үткәрүне оештыру турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 70 номерлы карары, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрүне оештыру турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 52 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карары:**

1. 2016 елның 20 ноябренә Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2017 елда Түбән Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 150 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме:

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу;

2. су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау;

3. территорияне Тышкы төзекләндерү объектларын төзү һәм ремонтлау, шул исәптән әлеге максатлар өчен төзелеш материаллары һәм кече архитектура формаларын сатып алу;

4. җирлекнең янгынга каршы су белән тәэмин итү объектларын төзү һәм карап тоту;

5. урам утларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту;

6. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә Карамалы Тау шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча халыкка хәбәр итәргә мөмкин: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт.

**Җирлек башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ф.Н. Шәмсиев**